Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

1945 70 2015

№7 (137)
7 май 2015 ел

## Җиңү көне белән!

**Бөек Ватан сугышында катнашкан һәм тылда хезмәт куйган кадерле ветераннарыбыз!**

**Казан университетының хөрмәтле хезмәткәрләре, укытучылары һәм студентлары!**


Сезне якынлашып килүче олы бәйрәм – Җиңү көне белән котлыйм! Бу көн – илебез өчен, фашизмга каршы көрәшкән бөтен дөнья өчен көтеп алган көн, кадерле җиңүне китергән көн!

Нацизмны җиңү тантанасын якынайтуга Казан университеты хезмәткәрләре дә үзләренең лаеклы өлешен керткән. Сугыш һәм хезмәт ветераннарына тирән ихтирам белән олы рәхмәтебезне белдерәбез! Сугыш кырларында ятып калган шәһитләрнең, Бөек Җиңүнең 70 еллык юбилеен каршылый алмаганнарның якты истәлеге алдында баш иябез, аларга дан җырлыйбыз!

Вакыт аяусыз, Җиңүнең соңгы солдатлары да бу якты дөньядан китеп бара... Без исән булганда, аларның исемнәре онытылмас, ата-бабаларыбыз кылган батырлык турындагы хатирә йөрәкләребездә мәңге сакланыр. Шанлы тарихыбызга карата үзгә караш барлыкка килүен һәм дистәләгән миллион гомерне алып киткән фаҗигале вакыйгаларның кабатлануын булдырмабыз. Безнең өчен 9 нчы Май – илебезгә ирек, бәйсезлек китерүчеләр белән ихлас горурлану билгесе, чиксез тәвәккәллек һәм Россиянең олы абруе символы. Бу көн күп милләтле халкыбызның уртак дошман алдында берләшә алуы, авыр көрәштә чыдам булып, бөтен дөньяны фашизмнан азат итүе турында гел искәртеп торсын!

Шул данлы көннәрнең шаһитларына, ветераннарга озын гомер, сәламәтлек һәм бәхет, ә аларның оныкларына үз халкы һәм Ватаны белән һәрчак горурланып яшәүләрен телим!

**Казан федераль университеты ректоры**
**Илшат Гафуров**




■ Александр Михайлович Малов. Влад Михневский фотосы

# Сугыш чоры журналистлары

**Зилия ХӘБИБУЛЛИНА,**
Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

БУ АРАДА БӨЕК ЖИҢҮГӘ БАГЫШЛАНГАН ЧАРАЛАР ШӘҺӘРДӘ ДАИМИ ҮТКӘРЕЛЕП ТОРА. КҮПТӘН ТҮГЕЛ ТАТАРСТАН ЖУРНАЛИСТЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ «БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫНДА ТАТАР ЖУРНАЛИСТЛАРЫ» ДИГӘН КОНФЕРЕНЦИЯ УЗДЫ.



Анда, КФУ студентларыннан тыш, Алабуга, Яшел Үзәннән килгән кунаклар да булды. Очрашуда фронт журналисты **Александр Малов** һәм Кремльдә урнашкан Бөек Ватан сугышына багышланган Мемориал-музей мөдире **Михаил Черепанов**, татар журналистикасы кафедрасы мөдире **Васил Гарифуллин** һәм «Мәдәни җомга» газетасы журналисты **Хәмзә Бәдретдинов** катнашты.

Чараны башлар алдыннан, барыбызның да игътибары өстәлдәге мемориал ташка төште. Аңа фронтта һәлак булган Татарстан журналистларының исемнәре уеп язылган. Һәлак булганнарны бер минут тынлык белән искә алдык. Белгечләр әйтүенчә, әлеге исемлек тагын да озынрак булырга мөмкин, чөнки ул чакта махсус берлек булмаган, барлык журналистлар да исәптә тормаган.

Конференциягә яраткан язучыбыз **Габдрахман Әпсәләмовның** оныгы **Альбина Әпсәләмова** башлап җибәрде. Ул бабасының «Ватан өчен сугышка» һәм башка газеталарда алып барган эшчәнлеге турында сөйләде. Г.Әпсәләмов фронттан үзе белән бик зур чемодан алып кайткан була: аның эчендә чын хәзинә ята. Әлбәттә, сүз алтын-мәрҗәннәр турында бармый, ул да булса, язучының сугыш елларында җыеп барган фронт газеталары, алардан кисеп алынган материаллар, шәхси блокнотлары, фотолар икән.

Бөек Ватан сугышы чорында 19 нчы фронтта барлыгы 16 татар фронт газетасы чыккан. Васил Гарифуллин сүзләренчә, Афзал Шамов ул чакта ук фронтта катнашкан язучыларны һәм журналистларны рәхмәт сүзләренә күмеп искә төшерәчәкләрен фаразлаган була. Александр Малов сүзләренчә, фронтта политработниклар бу газеталарны солдатларны җыеп кычкырып укый торган булган.

Михаил Черепанов исә бик күп сугышчыларның Ватан батыры исеменә лаек булып та, әлегә кадәр бүләкләнмәгән булуларын сөйләп китте. Солдат сугыш вакытында бәя биреп бетергесез батырлыклар кыла, әмма кайсыларыдыр бар дөньяга таныла, ә башка берәүләре батырлыклары турында истәлекләрне үзләре белән кабергә алып китә. Ни өчен? Җавап бик гади: якын тирәдә аларның кылган гамәлләрен күреп язар журналист булмаган.

Хәмзә Бәдретдинов исә студентларга конференциядәге чыгышларда исемнәре яңгыраган батырның туганнары белән сөйләшеп, кирәкле мәгълүматларны туплап, китап чыгарырга тәкъдим ясады.

# Яшьләргә үрнәк кеше

**Регина ШИҺАБЕТДИНОВА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

БӘЙРӘМ КӨННӘРЕ АРАСЫНДА КФУНЫҢ 92 ЯШЬЛЕК СУГЫШ ВЕТЕРАНЫ КӘРИМОВ ГАЗӘЛ МИРГАЛИМ УЛЫ БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ БӘХЕТЕ НАСЫЙП БУЛДЫ.

1938-41 нче елларда Газәл абый махсус артиллерия мәктәбендә укый. Сонрак уку йортын ябалар. Бүгенге көндә аның урынында КФУның Лобачевский исемендәге мәктәп-интернаты урнашкан. 41 нче елда аны Мәскәү артиллерия училищесына җибәрәләр. 2 еллык курс урынына барлыгы ярты елда укытып чыгаралар, чөнки илдә – сугыш! 4 дивизионның 3 нчесендә була Газәл абый. Ул вакытта куланылышка «Катюша», ягъни М-13 машиналары кергән була. 3 нче дивизионның хәрби юнәлешен пушкалардан бу машиналарга өйрәнүгә алмаштыралар.

1942 нче елның 18 нче апрелендә аларны фронтка җибәрәләр. 253, 254, 255 нче дивизионнар бер полкка берләштерелеп, Карелия фронтына (Петрозаводск, Мурманск) 10 нчы гвардия ату дивизиясенә ярдәмгә җибәрелә. Дивизион батареясының ут взводы командиры булган чакларын хәтта елмаеп искә ала Газәл абый: «Бары бер тапкыр «Катюша» снарядының шартлаганын күрдем. Төнлә булды бу. Кура җиләге төсендәге шарлар берсе артыннан берсе очты. Шундый матур!» – дип, көлә-көлә искә ала, ә күзләре моңсу. «Сугышта ник куркып торырга инде, – ди үзе. – Үтерсәләр, юк икән, иртәгә».

1943 нче елның 10 нчы сентябрендә каты яралана ул. Дусты Алеша белән күзәтү пунктын



эзләп кайтып барулары булган. «Якында ике снаряд төште. Шаярып кына, өченчесе безнеке инде дигән идем, кем белгән бит юраганым юш киләсен? Гадәттә, снаряд кырыйга очканда сызгыра, ә сиңа очканда кыштырдый. Кыйпылчыгы дустымның уң як чигәсе турына эләкте. 12 сәгатьләп ыңгырашып ятканнан соң, бүтән аңына килмәде. Минем уң як тез буынына һәм уң кулыма тиде», – дип искә ала Газәл абый.

44 нче елның июнь азагына кадәр – 9 ай госпитальләр алмаштыра ул. Шуның 7сен урын өстендә ята. Шул елның 4 нче июлендә рәсми рәвештә армиядән азат итәләр аны. Бихисап орден-медальләре арасында иң кыйммәтлесе дип «Кәрәшләрдә катнашучы билгесе»н атады Газәл абый.

Ул Казанга кайтып урнаша, сугыш беткәч гаилә кора. Якыннары белән киңәшләшкәч, Юридик институтка керергә карар кыла. Уку йорты, тулай торагы, ашханәсе, китапханәсе – бөтенесе бер бинада. Уңайлылык Газәл абый өчен бик мөһим, чөнки сугыш аны таякка таяндырган була. Уку йортын тәмамлагач, 1948 нче елда аспирантурага керә. Укытучылар җитмәү сәбәпле, шунда укыта да башлый. Институтны 52 нче елда таркаталар һәм Казан университеты нигезендә юридик факультет ачалар. Газәл Миргалим улы 42 ел гомерен университетка, студентларга багышлаган. Гаҗәп зур эш тәҗрибәсе булганлыктан, бик күпне белә, һәр нәрсәгә үз фикере бар аның.

«Безнең заманда үз эшенә тугры кешеләр эшли иде. Соңга калып килү дигән нәрсә юк. Сыйфат дәрәҗәсе югары булмаса да, эшкә мөнәсәбәт намуслы иде», – дип белдерә ветераныбыз.

Аны бик усал укытучы дип уйлаучылар да җитәрлек булгандыр. Шулай да бер укучысына сорау биргәне өчен генә имтиханда «5»ле куйган. «Ул кыз биргән сораулар фәнне чын-чынлап кызыксынып, аңлап өйрәнүче генә бирә ала, шуна куйдым», – дип аңлатты КФУның элекке доценты Газәл абый.

Бүгенге көндә сугыш ветеранының ике баласы, 5 оныгы һәм 4 оныкчыгы бар. Араларында гаилә башлыгының юлын дәвам итүче оныкчыгы Рената КФУның юридик факультетында укый.

Өлкән яшьтә булуына карамастан, Газәл абый тарихны яхшы хәтерли, бер дигән исәпли, хокукны биш бармагы кебек белә. Мондый ветераннар чын мәгънәсендә гаҗәпләндерә, алар бүген дә күп кенә яшьләргә үрнәк.

БҮГЕН БЕЗ ИЛ ТЫНЫЧЛЫГЫ, ЯКТЫ КИЛӘЧӘК ӨЧЕН БАШЛАРЫН САЛГАННАРНЫ ТИРӘН ХӨРМӘТ БЕЛӘН ИСКӘ АЛАБЫЗ. КЫЗГАНЫЧКА КАРШЫ, БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫНДА ИЛЕБЕЗ ИМИНЛЕГЕ ӨЧЕН КӨРӘШКӘН ҺӘМ ҺӘЛАК БУЛГАН КАЙБЕР СОЛДАТЛАРНЫҢ ГӘҮДӘЛӘРЕ КАЙДА ЯТУЫ ҺАМАН ДА БИЛГЕСЕЗ. ЭЗЛӘНҮ ЭШЛӘРЕ ДӘВАМ ИТӘ.

## Александр Суворов:
# «Соңгы солдат күмелмәгән, димәк, сугыш әле тәмамланмаган»

**Илмир ВӘЛИЕВ,** Математика һәм механика институты

Татарстанда «Кар десанты» командасы 1960 нчы еллар азагында Казан университетының география факультетында оеша. Максатлары изге: Бөек Ватан сугышында һәлак булган совет солдатларының җәсадләрен эзләү, аларның шәхесләрен ачыклау һәм җирләү эшләре. Бүген дә бу юнәлештә актив эшчәнлек алып барыла. Идарә, икътисад һәм финанслар институтының 3 нче курс студенты Раилә Хәйретдинова мәктәп елларыннан ук «Десантчылар» командасында.

**- Раилә, «Кар десанты» на ничек килеп эләктең?**

- Дөресен генә әйткәндә, гаиләбездә «Кар десанты»на бәйләнеше булмаган кеше юк! Әнием КДУның тарих факультетында укыганда, апам студент елларында ук «Десантчы» исемен алды. Минем бу эшкә 122 нче номерлы гимназиянең тарих укытучысы Җәүдәт Нәҗип улы Садыйков җәлеп итте.

**- Беренче экспедиция турында тулырак сөйлә әле.**

- Беренче экспедиция Җәүдәт абый җитәкчелегендә «Үлем үзәне»нә булды. 2012 нче елның август ае иде. Иң элек безне куркынычсызлык кагыйдәләре белән таныштырдылар, чөнки җир астында калган шартлаткыч матдәләргә юлыгырга мөмкин. Курку хисенә бирешмәсәк тә, экспедиция өчен сайланган Новгород өлкәсенең Мясной Бор авылы җирләренә аяк басуга, йөрәк бөтенләй икенче төрле тибә башлады. Таптап йөри торган җир астында үлеп калган солдат гәүдәләре булырга мөмкин бит! Казу, эзләнү эшләре вакытында шул чор вакыйгаларын күзаллыйсың. Әллә ничек булып куя... Җан өшегән мизгелләр кичерәсең. Илебез өчен кан койган солдат мәетен табып, аның исемен ачыклап туганнарына хәбәр ителсә, күңелдә горурлану хисе туа. Яу кырларында ятып калганнар алдында бераз гына булса да бурычлыбызны үтәгән кебек буласың.

**- Физик көч, психологик тотрыклылык таләп итә торган әлеге төр эшчәнлек егетләргә генә туры килә түгелме?**

- Арабызда минем кебек ихтыяр көче ник булган кызлар аз түгел. Минемчә, «Десантчылар» алып бара торган эшчәнлектә һәр кеше актив катнашырга тиеш.

**- Мәетләр янында гадәттә тагын нәрсәләр очрый?**

- Солдатларның кораллары, кирәк-ярак әйберләр, савытсаба, кашык һ.б. Гадәттә, алар Казан Кремлендә урнашкан Бөек Ватан сугышының Мемориал-музеенда урын таба. Музей мөдире **Михаил Валерьевич Черепанов** үзе дә эзләнү эшләрендә актив катнаша.

**- Экспедицияләрдән кала, әлеге хәрәкәт тагын нинди эшләр башкара?**

- 80 нче еллардан алып, «Кар десант»лары Икенче Бөтендөнья сугышында һәлак булган, хәбәрсез югалган татарстанлыларның исемлеген туплау белән шөгыльләнә торган республика «Хәтер» китабы өчен мәгълүматлар җыя.

**- Бүген «Десантчылар» командасына кемнәр килә?**

- Теләк белдерүчеләр арасында укучылар, студентлар, хәтта өлкән яшьтәгеләр дә бар. Республикабызның төрле шәһәррайоннарында Хәтер маршлары, агитбригадалар оештырыла.

***P.S.* «Кар десанты» яшьләрне хәрби-патриотик рухта тәрбияләүдә, Бөек Ватан сугышының батырлыгын мәңгеләштерүдә, Татарстан халыкларының сугышчан һәм хезмәт данын пропагандалауда гаять саллы эш башкара.**





Сугышның үзәгеннән килгән хатлардан солдатның җанын, аның хис-кичерешләрен сизеп буладыр. Газетабызның узган санында КФУ профессоры, фәлсәфәче Мансур Ибраһим улы Абдрахмановның фронт хатлары тәкъдим ителгән иде. Бу махсус чыгарылышта – шуларның дәвамы.



# «Байрагыма каным белән язган Антым чакыра алга барырга»






*Кәттә-Курган. 1.04.1942*

*Без, курсларны тәмамлап, төрлебез төрле якларга таралдык. Мин Кәттә-Курган (Үзбәкстан) дигән бер урынга эләктем. Монда моңарчы булган урыннардан яхшырак түгел. Шәһәрдән читтә землянкаларда торабыз. Кара-ком чүле якын булганлыктан, комга мохтаҗлык юк.*

*Мин хәзер – пулемет ротасы командиры. 1940 нчы елның апрель-май айларында мин булып кайткан Фин сугышы узган якларга барырга җыенабыз. Ул тарафны чистарту безгә тапшырылыр, ахрысы.*

*Хәзер исә башта ничек тә тизрәк сугышка китү уе гына.*

*Фронт. 14.05.1943*

*Бәгырьләрем Зәйнәп һәм Идия!*

*Сезгә кайнар фронт сәламнәре җибәреп калам. Инде монда килгәнгә дә бер ай булды, тормыш шулай үз җаена ага бирә. Бары тик һавада самолетлар үкерүе, снарядлар, миналар шартлавы, пулялар сызгыруы гына язгы табигатьнең матурлыгын бозып, якында гына үлем сагалап торуын искәртәләр. Ә без исә, кем әйтмешли, «На страх врагам» яши бирәбез...*

*Идияне күрәсем килә, тагын бер яңа рәсеменә карап, бер елда ничек үзгәргәнен-үскәнен күреп шатланасым килә. Миңа ул менә шушы мин ясаган рәсемдәгерәк төсле тоела...*

*Бәгырьләрем, сезгә сәлам миннән,*
*Бик сагынып язган хат аша;*
*Кызчыгымны өндә күрә алмый,*
*Төшләремдә күреп саташам.*
*Рәсемеңне ясаганда, кызым,*
*Карамадым синең йөзеңә;*
*Күңел, йөрәк кулны йөреттеләр,*
*Ышандым мин бары үземә.*
*Синең өчен, синең бәхетең өчен*
*Дошман сафларына ут ачам...*
*Рәсемеңне бүләк итәм сиңа*
*Ерак җирләр аша һәм кочам!*
*Икегезне дә каты үбеп, Мансур.*


**Кызыклы фактлар:**

- Бөек Ватан сугышы елларында Татарстаннан Кызыл Армия сафларына 500 меңнән артык кеше алына.
- 1941-1945 нче елларда Татарстаннан 22 меңгә якын хатын-кыз телефонист, телеграфист, 1500 дән артыгы снайпер булып сугышка китәләр.
- 1941 нче елның көзендә немец авиациясе Казан тимер юлына һөҗүм итә.
- 1941 нче елның җәендә Татарстан территориясенә Мәскәү, Ленинград, Украина, Белоруссиядән 70 зур завод-фабриканы күчерәләр.
- Бөек Ватан сугышы елларында Казан сырхауханәләрендә 334 меңнән артык солдат тернәкләнү курсы уза.
- Татар халкының 31 шагыйрь һәм язучысы, 22 журналисты сугыш кырларында ятып кала.
- Бөек Ватан сугышы елларында 14 хәлиткеч бәрелеш була.
- Үз тәне белән амбразураны каплаучы беренче кеше – Александр Панкратов.
- Сугышта 60 меңнән артык эт мина һәм снаряд эзләүдә файдаланылган.
- Советлар Союзы Герое исеме 87 хатын-кызга бирелгән.

# Алар моның өчен көрәшмәгән!

**Ландыш ГАРИФУЛЛИНА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Җирдән соңгы ветеран мәңгелеккә киткәч, без Җиңү бәйрәмен ничек каршы алырбыз? Сугышта катнашкан батырларны, тылда ачлы-туклы тормыш алып барган кешеләрне күреп калган буын буларак, безнең өчен әлеге бәйрәм мәгънәви кыйммәткә ия.



Ветераннар олыгая, 18 яшендә сугышка киткән егетләргә дә бүген 92. Бер гасырга якын гомер иткән алар! Үземнән 7-8 яшькә кечерәкләргә хәтта кызганып карыйм: аларга йөзләре балкып торучы, тик күзләре чиксез газап белән тулы тынычлык китерүчеләрне күрү бәхете эләкмәячәк, ә хәзергә алар бу очрашуның кыйммәтен аңларлык акылга ия түгелләр. Кызганыч хәл бу.

Бөек Ватан сугышы... Миллионлаган гомерләрне өзгән каһәр суккан сугыш. Әбиемнең әтисе Гаделша сугышка киткәндә, 4 яшьлек кызчык әле ни дә булса аңларлык булмаган. Ә бит мондый язмышка дучар булганнар шактый! Бәлкем, аларга да игътибар кирәктер? Сугыш чоры балаларын кем соң юатыр? Иртә-кич басу капкасына чыгып, әтисен көткәннәрнең гомерлек күз яшен кем сөртер? Сораулар чиксез күп. Әмма әле илдә һаман ветеран квартиры алырга чираты җитмәгән өлкәннәребез бар. 70 ел буена чират көткән өлкәннәр бит ул! Газиз илләре өчен 4 ел буе Җиңү таңын якынайтып та, тиешенчә рәхмәт ишетмәгән мескеннәр! Кулда күтәреп йөртәсе кешеләр, югыйсә!

Уйлана башласаң, сугыш ветераннары алдында уңайсыз булып куя. Өметләрен аклый алмадык, ахры. Алар җирдән риза булып китәрләрме? Украинадагы хәлләрне күреп, бер ветеран карт: «Без моның өчен пуляларга каршы бармадык. Без фашистны моның өчен тезләндермәдек. Нәрсә җитми адәм баласына? Тынычлап үлә дә алмыйм. Әз генә сәламәтлегем, әз генә егәрем булса, барыр идем. Оныкларымның тыныч яшәве өчен барыр идем», – диде. Күземә яшьләр килде. Украинада барган сугышларда рус сугышчылары катнашмаса да, без монда тынычта яшәсәк тә, бу ветеран Украинадагы сабыйларны үз оныклары дип атый. «Безнең өчен украиннар чит милләт түгел. Күпме татар, урыс кызы анда кияүдә, украиннарга күпме онык бүләк иттеләр!» – ди ул. Ул карт инде 3 ел урын өстендә, балалары тәрбиясендә. Әмма йөрәге тыныч түгел, җаны газаплана.

9 нчы май бәйрәмен ел да көтеп алам. Орден-медальләрен таккан, матур итеп киенгән ветераннарны күрер өчен, «бу Җиңү бәйрәмен дә күрделәр!» – дип сөенер өчен. Район үзәгендә аларны иң түргә, йомшак урындыкларга утырталар. Инвалид коляскасында, протез аякларда килүчеләр дә бар. Әмма елдан-ел урындыклар саны кимеп бара... Бары тик Мәңгелек ут кына аларның һәрберсен онытмыйча яна бирә.

Кайчагында дусларым белән уйланабыз: «Кешеләр Җиңү кадерен беләме, аңлыймы?» Юк кебек. Елга бер ветераннарга кызыл чәчкәләр бирү генә аларны аңлау билгесе түгел. Зур мәйданга җыелу да бәйрәм карау теләге генә. Бүләкләр тапшыру да шулай тиеш булганга башкарыла. Аяныч. Тик беркөнне мәктәп балаларының, җыелышып, ветеран картка өй эшләрендә булышырга баруын күргәч, туктап калдым: кешелек алай ук өметсез түгел, ләбаса! Укучылар үз теләкләре белән бара булып чыкты. «Тимурчылык»та аларга балалары тәрбиясендә яшәүче бер карт эләккән. Укучыларның күзләрендә мин чиксез шатлык, борчылу хисе күрдем! Минем белән сөйләшеп, вакыт әрәм итеп тормады алар: ашыга-ашыга китеп бардылар. Бәхетле, өметле балалар! Димәк, бер ветеран булса да игътибар, ихлас борчылу күрә! Алар менә шуның өчен пуляларга каршы барган!

Тормышыбызда бар да бар кебек: үз йортыбыз, ашарлык ризыгыбыз, кияр киемнәребез. Әти-әниебез исән-сау. Югары белем алабыз. Эшләмичә, тыныч кына укып йөрибез. Илдә тынычлык. Тик хәзерге кешеләрдә бер нәрсә җитешми: аңлау. Үткәннәрне һәм бүгенгене аңлау җитешми кешелеккә. Күпләр сугыш әллә кайчан булган, бүгенге тормыш аңа бәйле түгел дип кабул итә. Коточкыч фикер бит бу! Чынлыкта, бүгенге тормышыбыз әбиләребезнең тәсбихы сыман – аерым-аерым өзекләрдән төзелгән, әмма бер-берсенә бәйле булган бу өзекләр бөтен тәсбихны тәшкил итә. Бер бөртеге генә югалса да, тәсбих үз көчен югалта. Замана шаукымына ияреп, кешелектән чыгып баручы адәмнәргә шуны аңлатып булса, ветераннарыбыз тыныч күңел белән китәр иде... Алар бит шуның өчен пуляларга каршы барган!

Күңелемне борчый торган тагын бер нәрсә: татарларның 11 җәлилчесе бар, тик ни өчендер аларны күккә чөймибез. 11 әдәбиятчы сугышка китә һәм коточкыч үлем белән һәлак була. Аларның һәрберсенә һәйкәл куярлык бит!

Хатыннары тол каласын белеп, сызланып, тик ил киләчәге өчен балталарга башын салган! Туган йортлары, газиз әниләренең тавыш-тынсыз елавын тоеп, әмма киләчәк сугышларсыз булсын дип, алар, граната тотып, танк өстенә ташланган! Ач, ялангач, хәлсез килеш мылтык күтәреп, сугышка ыргылган. Без аларга тезләнеп рәхмәт укырга, игътибарсызлыгыбыз, салкын канлыгыбыз өчен гафу сорарга тиешбез!

# Рәхмәт әйтеп ата-бабага...

30 нчы апрель Казан федераль университетында Бөек Җиңүнең 70 еллык юбилеен искә алу кәне буларак тарихта калыр.

**Әдилә ГАЛИМОВА,**
Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты






Бәйрәм иң элек университет бакчасында мемориал такталар ачу белән башланса, аннан Муса Җәлил һәйкәле, «сковородка» янәшәсендә узды, соңыннан УНИКС концерт залында **«Студентлар язы – 2015»** гала-концерты белән дәвам итте. Тантананы университет ректоры **Илшат Гафуров** һәм Татарстан республикасының премьер-министры **Илдар Халиков** ачып җибәрде. Үз чыгышларында алар, хәтернең бик мөһим булуын искәртеп, Бөек Җиңүнең 70 еллык юбилее белән котлап, ветераннарга рәхмәт сүзләрен белдерделәр.

Гала-концерт программасы **Николай Николаевич Непримеров** – техник фәннәр докторы, профессор, Кызыл Йолдыз һәм II дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены кавалеры, сугыш чорында алган төрле медальләр иясе хатирәләреннән чыгып төзелгән. Николай Николаевич сүзләреннән чыгып, студентлар аның Бөек Ватан сугышы елларында кичергәннәрен сәхнәләштерәләр. Һәрбер чыгыш югары дәрәҗәдә профессиональ башкарылды. Алар күңел кылларына кагылып, тамчы-тамчы күз яшьләре булып, тамашачының битен юешләтте. Алкышлар тынмады, кичәнең кульминацион мизгеле 94 яшьлек ветеранның – **Николай Николаевич Непримеровның** – сәхнәгә күтәрелүе булды.





Влад Михневский фотолары

Гала-концертның икенче өлешендә яшьләрнең сәләтләре төрле жанрларда балкыды, фестивальдә җиңү яулаган студентларны бүләкләү тантанасы үтте. Бу елны Гран-при яулаган институтлар икәү – **Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты** белән **Идарә, икътисад һәм финанс институты**. Аларны җиңүләре белән чын күңелдән тәбрик итәбез. Фестивальне университет ректоры **Илшат Гафуров** җылы сүзләр белән тәмамлады: «Тагын бер кат бәйрәм белән котлыйм, әлеге ялларны күңелле уздырырга язсын. Иң мөһиме – якыннарыгыз янәшәсендә. Мөмкинлегегез булганда, вакытыгызны бергә уздырыгыз, чөнки беребез дә мәңгелек түгел!»

# «Әти канатым...»

**Алсу САХАБУТДИНОВА,** Идарә, икътисад һәм финанс институты

Шушы кырлар, урманнар, юллар буйлап минем бабайларым йөргән, алар да әлеге һаваны сулаган... Аларның тормышы, үткәне, язмышы мине күптәннән кызыксындыра. Кем мин, минем әби-бабайларым кемнәр, нәсел җепләре кая барып тоташа?

Дүртенче буын Минвәли бабам 1912 нче елда якты дөньяга килә. Харис бабай белән Хәдичә әби, балалары тууын бик шатланып көтеп алсалар да, гаиләнең зур мохтаҗлык кичергән чагы була. Тәкъдиргә ни язылган, шуны күрерсең, диләр бит халыкта. Минвәли бабай да тәкъдирендә язылган барлык сынаулар аша уза.

1919 нче елда, 7 яшьлек Минвәлине ачлыктан саклап калу нияте белән, авылдан эш эзләп китүче олы абыйсы Вагыйзга ияртеп җибәрәләр. Ачлыктан, эш таба алмаганнан алҗып, алар бер вокзалда туктыйлар. Аптыраганнан, Вагыйз бабай үзенең энесен бер дә белмәгән кыргыз гаиләсенә сатып җибәрергә килешә. Бала сизмәсен диптер инде, аны су эчәргә җибәрәләр, ә бу арада Вагыйз утырган поезд кузгалып китеп тә бара. Баланың булачак әти-әнисе: «Әйдә, безнең белән бара тор, хәзер абыең безне куып җитәр», - дип, аны тарантаска утыртып, Кыргызстан якларына алып кайтып китәләр.

Әлеге ир белән хатынның балалары булмый, Минвәлине үз балалары кебек яратып тәрбияләр. Алар акча юклыктан азап чикмәгәннәр, көтүе белән куйлары, сыер-бозаулары, атлары булган. Малай аларга кыргызча «атай» һәм «анай» дип эндәшкән.

Җырларда язылганча, җан тартмаса да, кан тарта дип әйтүләре бик дөрес шул. Минвәли бабайга 18 яшь тулгач, аны армия сафларына алырга тиеш булалар. Әтисе, улын армиягә җибәрер алдыннан, ике атын сатып, акчаларны егетнең итек балтырына яшереп куя, янәсе, армиядә кирәге чыгарга мөмкин.



Бабам бу уңайлы мизгелне кулыннан ычкындырмый: военкоматка баргач, коймасыннан сикереп чыгып, вокзалга йөгерә. Инде кая барыйм икән дип басып торганда, бер балалы хатынның татарча такмаклап елаганын күреп ала. Баксаң, бу хатынның туган ягы – Татарстанга кайтасы килә икән, тик акчасы юк. Татарстан дигәч, бабай, Чистай дигән шәһәрне исенә төшереп, ул хатынны үзе белән ала, әмма шундый шарт куя: хатын аны Тат. Волчье авылына кадәр озатып куярга тиеш.

Бабам, балачак мизгелләрен хәтерләп, Фәтхүч күле янына килә. Бу вакытта кырда эшләүче бертуган Хасәнә апасы, аны күреп, күңеле сизенеп, авылга таба йөгерә. Йортлары авыл уртасында урнашкан була, бабай үзе, танып, капканы ачып керә, йорт уртасындагы коены берничә кат әйләнеп, өй эченә уза. Бәрәңге әрчеп утыручы әнисе Хәдичәгә: «Әни, әни, мин – Минвәли, мин кайттым», – дип кычкырганын сизми дә кала. Инде улының исәнлегенә өмете өзелгән ана ышанмый. Шунда Хасәнә апасы кырдан кайтып керә: «Әни, әни, Минвәли кайткан, бу – Минвәли», – дип, егетне кочаклап ала.

Язмышы кушуы буенча, Минвәли бабай менә шулай, 1931 нче елда үз туган ягына кайтып, кандәшләре янында яшәп кала. Шуннан армиягә алына, ике ел кавалерист булып хезмәт итә. Армиядән исән-сау әйләнеп кайткач, бригадир булып та эшли. Аңа Кызыл Армия өчен алты тай карап үстерергә бирәләр, ул аларны күрше-күлән малайлар белән урман-кырларда көтеп йөри, тәрбияли.

Минвәли бабай 1937 нче елда авыл кызы Миннебәянгә өйләнә. Аларның өч балалары туа, ләкин икесе яшьли үлеп, бары әбием Мәкбүлә исән кала. Мәкбүлә әбиемә ата назын тоеп яшәргә язмаган икән: 1941 нче елда немец гаскәрләре совет җиренә бәреп керә, Бөек Ватан сугышы башлана. Атларны бик яраткан бабаем сугышка иң беренчеләрдән булып, атка атланып, кавалерист булып кергән.

Сугыш тарихка канлы хәрефләр белән язылды, миллионнарча кешенең гомерен кисте ул. Алар арасында минем Минвәли бабам да бар. Әбием Мәкбүлә һәм карт әбием Миннебәян аны гомерләре буенча көтеп, сагынып яшиләр. Сугышка кадәрге фотосурәтнең артына әле язарга гына өйрәнгән сабый шул чакта йөрәгендә йөрткән сүзләрне язып куйган була – «Әти канатым...»

# Сугыш - афәт

**Алсу НУРГАТИНА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Без сугыш чоры балаларының оныклары гына. Әби-бабаларыбыз сөйләгәннәрдән, аларның хис-кичерешләре аша гына Бөек Ватан сугышы ачысының кечкенә генә бер өлешен татыйбыз. Ләкин ул чор халәтен, мохитен бары тик шул «утны» кичкән кешеләр генә белә.

Кырмыска оясына таяк тыгып тузгыткандай, Сабантуй мәйданнарына кара козгындай ябырылган хәбәр килгәндә, әбиемә бары тик 9 гына яшь була. Сугышка аның олы абыйсын һәм әтисен алып китәләр. Тимер юлга шыкы-шыкы бәрелгән вагоннарга төялгәндә, чикләвек төше кебек тыгыз тәнле егетләр, Ватаны өчен утка керергә әзер булган ирләр бер атнадан әйләнеп кайтырбыз дип уйлый. Ләкин бу уйлар поезд составлары артыннан ияргән төтенгә кушылып тарала... Сугыш озакка, ә кемнәр өчендер бик озакка сузыла. Зур җиңү югалтуларсыз булмый, әбиемнең абыйсы да, әтисе дә сугыш кырында ятып калалар.

Сугыш дигән афәтләр булмасын иде җирдә... Болай да чикләнгән гомерне нигә чикләргә? Илебез матур, җир шары зур, киң бит!

DARELFØNYN университет
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир в.б. - Л.Р.Сабирова
Иҗат коллективы: И.Вәлиев, Р.Габдрахманова, А.Абдрахманова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Фолиант» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Профсоюзная, 17в.